
# БЕЗНЕҢ КӨН БАТЫРЛАРЫ





# МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯ




2022нче елның 24 февралендә Россия Украинада махсус хәрби операция башлады. Россия Президенты Владимир Путин бу карарны Донбасс халкын Киев режимы тарафыннан 8 ел буе барган геноцидтан һәм кысрыклаудан яклау өчен кабул итүе турында аңлатты. Президент НАТОның көнчыгышка таба киңәюен булдырмау кирәклеген дә әйтте. Донбасста яшәгән тыныч халык Россия төбәкләренә эвакуацияләнде. Алар өчен россиялеләр гуманитар ярдәм оештырды.

Күп кенә сәяси һәм хәрби экспертлар «махсус операция кыска вакытта төгәлләнәчәк» дип фаразласалар да, әлегә аның очы-кырые күренми.

# ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯ



Башта ярты ел буе махсус хәрби операция контракт килешүе нигезендә хезмәт итүчеләр көче белән барды. Хәрби операция өчен җаваплы затлар «илдә мобилизация булмаячак» дип ышандырсалар да, Россия Президенты Владимир Путин 21 сентябрьдән Россиядә өлешчә мобилизация башлану турында карар кабул итте. Россия оборона министры Сергей Шойгу ил буенча 300 мең ир-ат тупланганын белдерде. Һәр төбәктән хәрби операциягә озатылган кешеләр саны дәүләт серенә әверелде. Татарстаннан һәм аның һәр районыннан күпме ир-ат җәлеп ителгәне җәмәгатьчелеккә әйтелмәде.Хәрби операциягә озатылган егетләр арасында безнең якташларыбыз да бар. Менә алар: Курса Почмак авылыннан Мөхетдинов Рамазан Радик улы,Иске Му авылыннан Сафин Айдар Вахит улы,Иске Масра авылынан Габидуллин Нәсим Наил улы,Мөрәле авылыннан Абдуллин Алмаз Нәкыйп улы.Яр Чаллы шәһәреннән Нурисламов Рафаэль Рафис улы.




# САФИН
# АЙДАР
# ВАХИТ УЛЫ

Сафин Айдар Вахит улы 1994 елның 17 октябрендә Арча районы Иске Му авылында туа. Әнисе Кадрия апай лаеклы ялга чыкканчы Курса Почмак авылындагы фермада сыер савучы хезмәтен башкара, әтисе Вахит абый кран машинасында эшли. Айдарның өч апайсы бар: Алинә, Siринә, Миләүшә. Аларның өчесенен дә үз гаиләләре бар.











Иске Му башлангыч мәктәбен тәмамлагач, Айдар 5нче классны укырга Курса Почмак урта мәктәбенә килә. “4” һәм “5”ле билгеләренә генә укый, ударниклар сафыннан төшми. Класстан тыш эшдәрдә дә актив катнаша, спорт белән шөгыльләнә. Классташлары белән дустанә мөнәсәбәттә яши, өлкәннәрне хөрмәт итә, кечкенәләрне кыерсытмый. Айдар авылдашлары Радик һәм Айрат белән балык тотарга ярата. Класс белән походка баргач, балык тотып, классташларын тәмле уха пешереп сыйлаганнары әле дә истә. Яңа ел алдыннан кар сыннарын ясаганда да бу өч егет аерылып тора иде: үзләре теләк белдереп, бик яратып, матур итеп төрле сыннарны ясап куялар.

Уңышлы гына 9 нчы классны тәмамлагач, Айдар укуын «Арча аграр-сәнәгать һөнәр көллияте»ндә дәвам итә. Анда да егет тырышып укый, һөнәр ала.
Бер ел армия сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, Айдар Казанга “Нәфис Косметикс” заводына эшкә урнаша. Эшен яратып башкара. Айгөл исемле кыз белән яратышып өйләнешәләр, ике балалары: малайлары Илдан һәм кызлары Зилия туа. Туган нигезеннән читкә китми Айдар – әти-әнисе белән бергә Иске Му авылында яшиләр.



Махсус хәрби операциягә чакыру алгач та, Айдар Ватанны саклау изге бурыч икәнен аңлап хәрби хезмәткә китә. Әтисе, әнисе, хатыны, балалары, туганнары, авылдашлары – барыбыз да Айдарның исән-имин кайтуын көтәбез.
Кадрия апай белән Вахит абыйга подполковник В.Бояринның Рәхмәт хаты килгән. Анда батыр йөрәкле ул үстергәне өчен аларга рәхмәт сүзләре язылган.





Благодарственное письмо

Уважаемые
Вахит Гаизович и Кадрия Рафисовна!

Разрешите высказать Вам слова огромной благодарности за воспитание настоящего мужчины.

В ходе выполнения боевых задач в зоне СВО на территориях Луганской Народной Республики и Донецкой Народной Республики, благодаря смелым и решительным действиям Вашего сына, с зоны боевого соприкосновения были эвакуированы, оказана медицинская помощь и спасены жизни многих военнослужащих.

Его отваге и храбрости можно только позавидовать. Его поступки является хорошим примером для выполнения боевых задач и самое главное одержании победы над врагом.

Именно Вы воспитали такого отважного и мужественного бойца.

Вы по праву можете гордится таким защитником Великой России!


С уважением
Командир войсковой части полевая почта 29660
подполковник В. Боярин



Махсус хәрби операция барышында күрсәткән батырлыклары өчен 2024 нче елның 5 нче августында ”Участнику специальной военной операции” ,2024 чне елның 2 нче октябрендә II дәрәҗәдәге “За воинскую доблесть” медальләре белән бүләкләнде. Без Айдар белән горурланабыз.





# МӨХЕТДИНОВ РАМАЗАН РАДИК УЛЫ


Мөхетдинов Рамазан Радик улы 2001 нче елның 16 ноябрендә  Арча районы Курса Почмак авылында туган.Рамазанга 6 яшь вакытта, 2007 нче елның 14 нче августында әтисе – Радик вафат була.Әнисе-Чулпан  Казан шәһәрендә хастаханәдә шәфкать туташы булып эшли.Энесе Марат Казан энергитика көллиятендә белем ала.

Рамазан Мөхетдинов  2008 нче елның 1 нче сентябрендә Арча районы Курса Почмак урта мәктәбенә укырга керә.Мәктәптә укыганда алдынгы  укучылар рәтендә була.Бию, җыр, көрәш түгәрәкләренә бик теләп йөри.Районда үткәрелгән конкурсларда катнашып, югары уңышларга ирешә.Дәрестән тыш вакытларда Рамазан  авыл яшьләрен җыеп, кышын чаңгыда йөри, хоккей, футбол уйный.





Рамазан мәктәптә укыганда шигырьләр дә язарга ярата.Беренче укытучысына багышлап язган шигыре район гаҗитендә басылып чыга.




Нинә чакрымнарга
тулыр икән
Мәктәпләргә
йөргән шушы юл.
Һәр туган көн
укытучы көне,
Укытучы елы –
һәрбер ел.
Үлчәмәгез аның
хезмәтләрен
Бизмәннәргә салып
бу елда.
Белем чаткыларын
тарата ул,
Сукмаклары изге
шул юлда.

**Берүземә – ике әни**

*(Сабирҗанова
Нурзилә Бари кызына)*

**Рамазан МӨХЕТДИНОВ,
Курса–Почмак мәтәбенең
2 сыйныф укучысы**

Әни кебек
ягымлы сез,
Әни кебек сөйкемле.
Кайвакыт берүземә
Ике әни шикелле.
Белем иленә
җитәкләп
Мине алып кердегез.
Кеше булсын
бу бала дип
Үтә һәрбер көнегез.
Хезмәтегез авыр, шуңа
Хөрмәт итү кирәктер.
Сабыр да сез,
түземле дә,
Сездә ике йөрәктер.



Нурзилә Бариевна!
Гомерлеккә калып хәтеремдә
Мәктәп капкасыннан атлавым
Мин – кечкенә малай, әни
кулын
Ычкындыруымнан курыктым
Шул вакытта кояш кебек балкып
Сез килдегез минем каршыма
Рәхәт булып китте күңелемә
Әй куанган идем шуңсына
Ак кәгазьгә тамга сала-сала
Без юл алдык белем иленә
Сезнең көч куюның, тырышлыкның
Нәтиҗәсе бүген күренә
Яшь йөрәккә канат тибрәтүнең
Әллә ничек серен беләсез
Җырга, биюгә теләк уяттыгыз
Арча – Казаннарда булыбыз
Югары сыйныфка атласак та
Сезне онытмабыз апабыз
Сез хөрмәткә, ихтирамга лаек
Сезгә уңыш теләп калабыз
Рамазан.

9 нчы сыйныфны яхшы билгеләргә тәмамлагач, укуын Арча педагогия коллиятендә дәвам итә.Үзенең беренче укытучысы Сабирҗанова Нурзилә Барый кызы кебек , ул да башлангыч сыйныф укытучысы булырга хыяллана.  Көллияттә уку дәверендә үзен яхшы яктан гына күрсәтә. Үзенең елгыр, тырыш, җитез, ярдәмчел булуы аның дуслары күп булуга да этәргеч ясый.







Педагогия көллиятен тәмамлагач Армия сафларына алына. Ул Мәскәүдә 154 нче комендант Преображенск полкында бер ел хезмәт итә.Армия сафларында хезмәт иткәндә бик күп мактау кәгазенә ия була.Җиңү парадында катнашып “За участие в военном параде в День Победы” медале белән бүләкләнә. 2022 нче елның июнендә хезмәт вакытын тәмамлап туган авылына кайта.







Батыр егет-Рамазан армия сафларыннан кайтып озак та үтми, сентябрь аенда  махсус хәрби операциягә чакыру ала. Ул махсус хәрби операциядә катнашу өчен чакыру алуны Ватан чакыруы дип кабул итә. “ Ватанны сакларга без дә бармагач,кем барыр ?”-ди ул.Анда да егет кечкенәдән алган тәрбияви сыйфатлары нык кирәклеген раслый: иптәшләренә ярдәм итә, кирәк чакта терәк була белә, авырлыкларга бирешми.

Махсус хәрби операция барышында күрсәткән батырлыклары өчен “За боевые отличия”, II дәрәҗәдәге “За воинскую доблесть”,”Участнику военной операции” медальләре белән бүләкләнде. Рядовой Мөхетдинов Рамазаның хәрби часть командиры О.В.Боярин тарафыннан әти-әнисенә “Рәхмәт хаты” килеп иреште.







# Мин еламыйм.
# Рамазан елаганны  яратмый.

Арча хәбәрләре
Гөлсинә Зәкиева,2 июнь 2025

Рамазан Мөхетдинов июльдә армиядән кайта, сентябрьдә мобилизацияләнеп махсус хәрби операция зонасына китә.
Аның турында без беренче булып педагогика көллиятендәге укытучысы, сыйныф җитәкчесе Флера Шакировадан ишеттек.
– Кулына диплом алганнан соң армия сафларына хезмәт итәргә китте. 2022 елның җәендә кайтты. Аннан... тагын хәрби хезмәт. Рамазан белән еш аралашып торабыз. “Минем өчен борчылмагыз, бар да яхшы”, – ди ул. Укыган вакытта да, хәзер дә зарланганын ишеткәнем юк. Нинди авыр булуын үзе генә белсә дә, безгә сиздерми. Быел чыгарылыш курс студентларына теләкләрен җиткереп, видеоязма да җибәрде. Тантана барышында аны тыңлау иң дулкынландыргыч мизгелләрнең берсе булгандыр, мөгаен, – диде Флера ханым.

Менә без Курса-Почмакта, Рамазан Мөхетдиновның туган йортында. Әнисе Чулпан ханым белән фотосурәтләрен, медальләрен карап утырабыз. Ана улының фотоларын зурайтып ясаткан да, өстәлгә тезеп салып куйган. Түр якка керүгә улы каршы аладыр кебек тоела аңа. Медальләре дә шунда – “Хәрби батырлыгы өчен”, “Сугышчан батырлык өчен”, “Сугышчан хәрәкәтләр ветераны”, “Җиңү парадында катнашкан өчен”.

– Әйе, Преображенск полкында хезмәт итте ул, – диде Чулпан ханым. – Армиягә барам, диде. Алдан ук әзерләнде. Спорт белән шөгыльләнде, мускуллар үстерде. Хәрби комиссариатка китте. Буе да, сәламәтлеге дә шушы полкка җибәрү өчен туры килде. Метр да 87 сантиметр иде, анда баргач метр да 90 сантиметр булды. Үсеп китте. Ике тапкыр янына бардык. Берсендә ант кабул иткәндә, икенчесендә Җиңү парадына. Ул шунда катнашты. Дөрес, безне парадка кертмәделәр, әмма әти-әниләр өчен махсус күрсәттеләр. Хезмәт иткән урынында командирлары да бик яратты үзен. Рәхмәт хатлары килде. Калырга өндәделәр. Риза булмады. Махсус хәрби операция башланыр, дип кем уйлаган. Анда киткәндә егерме генә яшь иде.

Чулпан үзе Буа кызы. Медицина училищесын тәмамлап, Казанга онкология диспансерына шәфкать туташы итеп җибәрәләр. Дүрт ел эшләгәннән соң тимер юл хастаханәсенә күчә. Унбиш ел хирургия бүлегендә шәфкать туташы була. Шунда операциядән соң дәваланып яткан Курса-Почмак егете Радик белән таныша. Һәм авылга, төп йортка килен булып кайта. Уллары туа. Кайнанасы рамазан аенда туганга оныгына Рамазан, дип исем куйдыра. Чулпанның үзенең дә күңелендә йөрткән исемнәре була, әмма кайнанасына каршы төшми.

Декрет ялыннан соң да ул Казанда эшләвен дәвам итә. 2006 елда авылда йорт сатып алып, гаилә башка чыга. Ире генә озын гомерле булмый. Йөрәк авыруы аны бик иртә якты дөньядан алып китә. Ул чакта икенче уллары Марат туган гына була.

– Икесе дә яхшы укыдылар. Баянда уйнадылар. Рамазан үзлегеннән өйрәнде. Спорт белән шөгыльләнеп үстеләр. Беренче сыйныфтан биергә йөрделәр. Курса-Почмак мәктәбе һәр яктан бик көчле бит. Укытучылары, хәзер мәктәп директоры Нурзилә Бариевна бик тырышты. Бию түгәрәге оештырды, белгечләр чакыртты, киемнәр тектертте. Мәктәпне тәмамлаганчы бик яратып шөгыльләнде балалар, – диде Чулпан Мөхетдинова.

Мәктәптән соң Рамазан педагогика көллиятенә керергә була. Физкультура укытучысы булу турында хыяллана. Тик ул төркем тулган булу сәбәпле, бераздан күчәрмен, дигән максат белән, башлангыч сыйныфлар укытучылары әзерләү төркеменә гариза бирә. Курс җитәкчеләре Флера Шакированы шулкадәр үз итә, төркемдәшләренә дә ияләшә, аннан һич кенә дә китәсе килми егетнең. Шулай башлангыч сыйныфлар укытучысы һөнәрен үзләштереп чыга. Армия сафларында хәрби бурычын үти. Аннан...

– 2022 елның 26 сентябрендә махсус хәрби операция зонасына китәргә повестка килде, – диде Чулпан ханым. – Бер ай Казанда экспода тордылар. Ноябрь башында юлга кузгалдылар. Белгород юнәлешенә. Басуда окоплар казыдылар, шунда яшәделәр. Кышы да ике атна гына булды ул елны. Бертуктаусыз яңгыр яуды. Пычрак, машиналар, танклар да ерып йөри алмый, бөтен җирдә мина, агач полосасыннан беркая чыгып булмый, диде Рамазан бер сөйләшкәндә. Бер-ике егет кенә кибеткә, ашханәгә чыгып керә алган.

Өстәвенә әле ашханәне дә шартлатканнар. Менә шундый шартларда да яшәделәр. Әмма мине борчымас өчен микән, зарланмады Рамазан. Аннан гуманитар ярдәм оештырылды, посылкалар җибәрдек. Акчалар җыеп, “УАЗ” машинасы алдылар. Посылкаларны алырга машина белән йөри башладылар.

Төнге разведчик Рамазан. Дроннар очырта. Көндез ял итә, төнлә разведкада. Дүрт тапкыр кыска вакытлы ялда булып киткән. Бер ел буе кайта алмаган. Язын март аенда гына ялда булып киткән.

– Ардырган. Бер дә китәсе килмәде. Озатырга баргач, саубуллашмыйбыз. “Киттем” – шуның белән шул. Мин еламыйм. Үземне тыеп торам. Рамазан елаганны яратмый. Район җитәкчеләренә, волонтерларга, бөтен район халкына гуманитар ярдәм өчен рәхмәт җиткерергә кушты. Бик зур ярдәм итәләр, ана буларак миннән дә чиксез зур рәхмәт. Гуманитар ярдәм җибәрделәр. Дроннар алырга акча җыйдылар. Элеккеге район җитәкчесе Илшат Нуриев үзе дә бик булышты. Авыл халкының, туганнарның, дусларның ярдәме зур булды. Иремнең туганы Ләйсәния бөтен туганнарны туплап, бергә посылкалар җибәрделәр. Мәктәп коллективы генераторга кадәр алды, башкасын әйткән дә юк.

Көллияттәге курс җитәкчесе Флера Шакирова Рамазан белән элемтәне югалтмады, ярдәмнән ташламады, – диде Чулпан ханым. – Көн саен улым белән телефоннан сөйләшәбез. Мин кичке якта, төнге сменасы алдыннан элемтәгә чыгам.

Тавышын ишетсәм дә, аның исәнлегенә шатланып туя алмыйм. Ике тапкыр үлем аны читләтеп үткән. Беренчесендә снаряд шартлаган, ул могҗиза белән исән калган. Икенчесендә снайпер пулясы колак яныннан гына чыжлатып үтеп киткән. Суга барганнарын саклап кына торганнар. Бәлки, зыкымы булгандыр да, әйтми. Минем өчен иң мөһиме, ул исән.

Өйләре зур, бик матур урында урнашкан. Бакчалары бар. Чулпан ханым өйдә мәш килүдән, бакчада эшләүдән үзенә тәм һәм тынычлык ала, беразга онытылып тора. Аннан атна саен икенче улы ялга кайта.

– Маратка 17 яшь. Энергетика көллиятендә белем ала. Ул минем юанычым да, ярдәмчем дә, – ди Чулпан. – Тизрәк махсус хәрби операция тәмамланып, Рамазаным исән-сау кайтса, тормышлар түгәрәкләнә. Бөтен аналарга да балаларын исән-имин күтеп алырга язсын.








STRESS LESS
keep smiling


Мухутдинов
Рамазан
Радикович
приказом Министра обороны Российской Федерации
от «09» 05 2022 г. № 372
награжден(а) медалью Министерства обороны Российской Федерации
«ЗА УЧАСТИЕ В ВОЕННОМ ПАРАДЕ В ДЕНЬ ПОБЕДЫ»
командир войсковой части 01904
(должность, воинское звание,
полковник
инициалы имени, фамилия и подпись лица,
С. Бессонов
вручившего медаль)
М.П.




БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО
Уважаемая Чулпан Масгутовна


Мухутдинов
Рамазан
Радикович
приказом КГрВ(С) Ц
от «04» мая 2023 г. № 26 дсп
награжден(а) медалью Министерства обороны Российской Федерации
«ЗА БОЕВЫЕ ОТЛИЧИЯ»
Командир В/ч пп 29660
(должность, воинское звание,
п-к
инициалы имени, фамилия и подпись лица,
И. Долматов
вручившего медаль)
Медаль № 59851
М.П.


ЗА БОЕВЫЕ ОТЛИЧИЯ


Мухутдинов
Рамазан
Радикович
приказом Ком. 1 гв. ТА ЗВО
от «19» ноября 2023 г. № 322
награжден(а) медалью Министерства обороны Российской Федерации
«УЧАСТНИКУ СПЕЦИАЛЬНОЙ ВОЕННОЙ ОПЕРАЦИИ»
М.П.




Мухутдинов
Рамазан
Радикович
приказом КВ ЗВО
Российской Федерации
от «12» октября 2023 г. № 45 дсп
награжден(а) медалью Министерства обороны Российской Федерации
«ЗА ВОИНСКУЮ ДОБЛЕСТЬ»
М.П.





# ГАБИДУЛЛИН
# НӘСИМ
# НАИЛ УЛЫ

Габидуллин Нәсим Наил улы 1999 нчы елның 12 нче маенда Арча районы Иске Масра авылында туган. Әнисе Гөлүсә – Курса Почмак почта бүлекчәсендә хат ташучы, әтисе Наил Яңа Чүриле психионевралогик интернатында санитар булып эшли. Абыйсы (гаиләле) һәм энесе бар.

Нәсим Габидуллин Иске Масра башлангыч мәктәбеннән соң укуын Курса Почмак урта мәктәбендә дәвам итә. Мәктәптә гыйльми белем белән беррәттән мәдәни яктан ул үзен сыный: баян түгәрәгенә языла. Нәсим, буш вакыты булса, балык тотарга ярата. Оештыру сәләте көчле булу егеткә ярдәм итә: авыл яшьләрен җыеп, кышын чаңгыда йөри, хоккей, футбол уйный, ә сабан туенда ат чабышында катнаша.







9 нчы сыйныфны яхшы билгеләргә тәмамлагач, укуын Арча педагогия коллиятендә дәвам итә Нәсим, татарча көрәш түгәрәгенә йөри башлый. Түгәрәккә йөрү акрынлап үз нәтиҗәләрен дә бирә: бер-бер артлы җиңүләр килә. Һәр җиңү киләчәккә өмет уята, рухи яктан аны үстерә, көчен арттыра. Нәсим көрәш буенча Арча район яшьләре арасында төп батыр булып танылa. Армиядә чыныгу алган егет соңрак Татарстан, Россия күләмендәге ярышларда зур җиңүләр яулап, көрәш буенча “Россиянең спорт мастеры” дәрәҗәсенә ирешә.










Педагогия көллиятендә белем алганда, баянда уйнау серләрен тагы да тирәнтен үзләштереп, сәхнәләргә чыга Нәсим. Егетләр белән җырлау, төрле конкурсларда, спорт ярышларында катнашу дисеңме: егет тик тормый. Үзенең елгыр, тырыш, җитез, ярдәмчел булуы аның дуслары күп булуга да этәргеч ясый. Ул махсус хәрби операциядә катнашу өчен чакыру алуны Ватан чакыруы дип кабул итә. Анда да егет кечкенәдән алган тәрбияви сыйфатлары нык кирәклеген раслый: иптәшләренә ярдәм итә, кирәк чакта терәк була белә, авырлыкларга бирешми.







Махсус хәрби операция барышында күрсәткән батырлыклары өчен “За боевые отличия”, I, II дәрәҗәдәге “За воинскую доблесть” медальләре белән бүләкләнде. Отделение командиры, кече сержант Габидуллин Нәсимнең хәрби часть командиры О.В.Боярин тарафыннан әти-әнисенә “Рәхмәт хаты” килеп иреште.








1234 мотострелковый полк

Почетная
ГРАМОТА

НАГРАЖДАЕТСЯ

сержант
Габидуллин Насим Наилевич

За мужество, отвагу и самоотверженность при выполнении воинского долга в зоне проведения специальной военной операции в ЛНР, ДНР, Запорожской и Херсонской областях, а также на Украине, и в ознаменование Дня Победы.

КОМАНДИР ВОЙСКОВОЙ ЧАСТИ ПП 29660

полковник А.Фунцев

9 мая 2025 г





БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО

Уважаемые Наиль Закариевич
и Гелюса Марсовна

Обращается к Вам командир воинской части, в которой проходит службу Ваш сын- командир отделения младший сержант Габидуллин Насим Наилевич.

За время службы в полку Ваш сын зарекомендовал себя как добросовестный, смелый, исполнительный военнослужащий. Находясь в зоне проведения специальной военной операции, где ежедневно возникают угрозы жизни и здоровью, младший сержант Габидуллин мужественно и профессионально выполняет задачи, которые ему ставят командиры. Неоднократно первым шёл туда, где требовалась помощь боевым товарищам, словом и делом помогая в трудные минуты боевой обстановки. За время службы получил очередное воинское звание "младший сержант".

Насим пользуется заслуженным уважением у командиров и подчиненных, является примером в исполнении воинского долга. На таких защитниках Родины как Ваш сын держится наша Россия.

Командование подразделения и воинской части благодарит Вас за достойное воспитание сына, отличного воина и человека. Вы можете им гордиться.

Желаем Вам крепкого здоровья, долгих лет жизни, достатка, успехов во всех добрых начинаниях, и конечно дождаться своего сына живым и здоровым.

С уважением,
Командир войсковой части 29660
подполковник Боярин В.О.





# АБДУЛЛИН АЛМАЗ НАКЫЙП УЛЫ










Абдуллин Алмаз Накыйп улы 1992 елныҢ 10 декаберендә Арча районы Мөрәле авылында туа. 1994-1998 елларда Мөрәле балалар бакчасына йөри. 1999 елда Мөрәле башлангыч мәктәбенә укырга керә. 2002 елда Сеҗе урта мәктәбенә 5 нче сыйныфка укырга килә. Уку дәверендә яхшы билгеләргә генә укый, тәртипле, эш сөючән, иптәшләре белән яхшы мөнәсәбәттә була.

2011 елны мәктәпне тәмамлап Казан гуманитар техникумына укырга керә.

2011 елның ноябрь аенда Армия сафларына алына.Армиядән 2012 елда кайта. Техникумны читтән торып тәмамлыий.

2013 -2019 елларда «Вентана» фирмасында менеджер булып эшли.

2019-2022 елларда Сочида эшли.

2022 елнын 14 августында махсус хәрби операциядә катнашу өчен контракт төзеп илебезне сакларга китә.


Алмаз курку белмәс, уз сузендә нык торучы егет.

Хәзерге вакытта 3 нче елын 13714 в/ч хезмәт итә.



# НУРИСЛАМОВ
# РАФАЭЛЬ
# РАФИСОВИЧ

Нурисламов Рафаэль Рафис улы 1985 елның 15 декабрендә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә (ул чакта Брежнев шәһәре) беренче бала булып дөньяга килә. Балалар бакчасында тәрбияләнә, 13 нче урта гомуми белем мәктәбендә укый, югары белем ала (Камский Институт Экологии и Охраны Труда). Армиядә Түбән Новгород шәһәрендәге тимерьюлчылар гаскәрендә хезмәт итә. Гаилә кора. Хатыны Ильвира белән Менделеевкий районы Тураево авылында яши, ике бала үстерәләр. Кызы Регинага – 14, улы Инсафка 12 яшь. Әти-әнисе Арча районы Иске Масра авылында туып үскән.








2022 нче елның 28 нче октябрендә мобилизацияләнә. 430 нчы мотоукчылар полкында хезмәт итә. Кызы Регина болай дип яза:

“Сез барысын да беләсез, 2022 нче елның февралендә Украинада махсус хәрби операция башланды. Күп кенә ир-атларны мобилизацияләделәр, ә кемдер үз теләге белән сугышка китте.

Минем әтием Нурисламов Рафаэль Рафис улы да читтә калмады.2022нче елның 27 нче октябрендә без әнинең энесе Ильвир абыйны Украина территориясендә хезмәт итүгә әзерлек өчен Казанга озаттык. Кич белән гаилә дустыбызның туган көненә җыендык. Кинәт әтинең кесә телефоны шалтырады, аңа повестка килгәнен һәм икенче көнне иртән Казанга китәргә кирәклеген әйттеләр. 28 октябрь көнне без әтине Менделеевск шәһәре военкоматыннан Казанга озаттык.







Казандагы әзерлек чорында без гаиләбез белән берничә тапкыр аның янына бардык. Очрашу-күрешү сәгатьләре бик тиз узып китә икән шул. Бер ай узгач, әни миңа һәм энемә әтиемне Ватанны сакларга Украинага җибәрүләре турында хәбәр итте.Безнең өчен иң авыр чор башланды: әтинең шалтыратуын түземсезләнеп көтү, сөйләшкәндә күз яшьләре аша елмаю, отпускага кайту шатлыгы һәм озаткандагы иң авыр минутлар, күз яшьләре...”

2025 нче елның февралендә Нурисламов Рафаэль каты яралана.  Штаб лазаретында аңа беренче ярдәмне күрсәтәләр, Донецкий, Ростов на Дону, Кисловодский, Казан госпитальләрендә берничә операция була. Хәзерге вакытта дәвалану курсы уза.

Күрсәткән батырлыклары өчен  2024 нче елның гыйнварендә  -  «УЧАСТНИКУ СПЕЦИАЛЬНОЙ  ВОЕННОЙ ОПЕРАЦИИ»,  2024 нче елның ноябрендә -  “ЗА ВКЛАД В УКРЕПЛЕНИЕ ОБОРОНЫ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ”, 2025 нче елның апрелендә “ЗА СПАСЕНИЕ ПОГИБАВШИХ” медальләре белән бүләкләнә.










# РӘХМӘТ СЕЗГӘ, БАТЫРЛАРЫБЫЗ!